**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 26.12.2020** **№ 973**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау районы прокуратурасының 2020 елның 15 декабрендәге 02-08-02-2020 номерлы протесты нигезендә, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты,КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү турында» карарына (23.09.2019 № 1617, 02.04.2020 № 339, 15.07.2020 № 547 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенең 9 п., 28 п. - «төшереп калдырырга».

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 02 апрелендәге 339 номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин